РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Большекармалинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Карамалы**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

ул.Центральная, 4,с.Большие Кармалы, 422830
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 04308893 ОГРН 1021605953951
ИНН/КПП 1622001788/162201001

Узэк урамы , 4,Олы Карамалы авылы, 422830,
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 04308893 ОГРН 1021605953951
ИНН/КПП 1622001788/162201001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.11.2019 № 3

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Малаевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2019 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Малаевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясе, Малаевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Малаевка  авылында поселок эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау;;
- Малаевка авылында чүп үләннәрен чабу (җәйге-көзге чор) .

« ӘЙЕ»                                                  «ЮК».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга):

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк урамы, 4;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа  авылы, Тукай урамы, 16,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуника-ция челтәрендә 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы  авыл җирлеге
башлыгы                                                                     Э.И.Байдамшин